| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**25.05.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1148** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы, 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү хакында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 июлендәге 1840 номерлы, 2016 елның 20 июлендәге 1894 номерлы, 2016 елның 2 августындагы 1996 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип тану турында

Зеленодольск шәһәр судының 2017 елның 30 декабрендәге 2-1548/2017 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Югары судының 2018 елның 26 апрелендәге 33-2648/2018 номеры эшенең апелляция билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының«Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы карары кушымтасына, «Васильево штп, Стахановская ур., 62 нче йорт»-152 пунктны төшереп калдырырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карарының кушымтасына, «Васильево штп, Стахановская ур.,62 нче йорт»-304 пунктын төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Васильево штп, Стахановская урамы, 62 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2016 елның 15 июлендәге 1840 номерлы, «Васильево штп, Стахановская урамы, 62 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2016 елның 20 июлендәге 1894 номерлы, «Васильево штп, Стахановская урамы, 62 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт

объектларын тартып алу турында» 2016 елның 02 августындагы 1996 номерлы карарларының үз көчен югалтуын танырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты » МКУ;

- торак урыннар милекчеләренә.

5. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин